**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2025 елның «29» маеннан № 128

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының «Ажаган» яшәү урыны буенча яшүсмерләр клубы» муниципаль бюджет учреждениесенең түләүле хезмәтләр күрсәтү бәяләрен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының муниципаль бюджет учреждениеләре тарафыннан түләүле һәм керем китерә торган башка хезмәтләр күрсәтү турындагы нигезләмәләрне раслау хакында» 2023 елның 29 декабрендәге 40-325 номерлы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 15 маендагы 55-426 номерлы карары нигезендә, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының «Ажаган» яшәү урыны буенча яшүсмерләр клубы» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр күрсәтүне тәртипкә салу максатларында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының «Ажаган» яшәү урыны буенча яшүсмерләр клубы» муниципаль бюджет учреждениесенең кушымтада бирелгән түләүле хезмәтләр күрсәтү бәяләре прейскурантын расларга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https:/novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче Е.А.Тарнавский

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025 елның «29» маендагы
128 номерлы карары белән
расланган

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының «Ажаган» яшәү урыны буенча яшүсмерләр клубы» муниципаль бюджет учреждениесенең кушымтада бирелгән түләүле хезмәтләр күрсәтү бәяләре прейскуранты

| № т/б | Хезмәтнең исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум) | Хезмәт күрсәтү берәмлеге | Шөгыльләнүчеләр саны |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Остаханәләрдә дәресләр үткәрү (мастер-класслар, робототехника һәм башка чаралар) | 150 | 1 чара | 1 кеше |
| 2 | Бию залында дәресләр (йога, стретчинг, фитнес, бию) үткәрү | 200 | 1 сәгать | 1 кеше |
| 3 | Vr-күзлек приставкасында уеннар һәм турнирлар үткәрү | 150 | 1 сәгать | 1 кеше |
| 4 | Тавыш яздыру хезмәтләре (яздыру, эшкәртү, музыкаль композицияләр белешү, репетицияләр һәм мастер класслар үткәрү) | 1500 | 1 җыр (композиция) | 1 дән 5 кешегә кадәр |
| 5 | Яктырту җиһазлары белән фотостудия хезмәтләре күрсәтү (фотосессияләр, мастер-класслар үткәрү) | 1000 | 1 сәгать | 1 дән 10 кешегә кадәр |
| 6 | Тавыш яздыру студиясендә музыка коралларында шөгыльләнү (шәхсән) | 200 | 1 сәгать | 1 дән 5 кешегә кадәр |
| 7 | Тематик квестлар, квмзлар оештыру һәм үткәрү | 100 | 1 сәгать | 1 кеше |
| 8 | Ноутбук арендалау | 100 | 1 сәгать | 1 кеше |